## Авылдашыбыз – сугыш батыры

**/Җиңүнең 76 еллыгына/**



Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашлар арасында **Хафизов Шакир Шәфик улы** аерым урын билəп тора. Ул 1918 нче елда Түбəн Майна авылында Хафизов Шәфик бабай гаиләсендә дөньяга килә. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1938 нче елда хәрби училищега укырга керә. Аны 01.05.1941 тәгәлләп, лейтенант званиесе алып чыга. Шулай итеп, Бөек Ватан сугышын Шакир Хафизов кадровый офицер булып каршылый. Хәрби хәрәкәтләрдә Көньяк-Көнбатыш фронтта 10.09.1941 катнаша башлый. Атна-ун көн сугышып 19.09.1941 беренче тапкыр авыр яралана.

Госпитальдән чыккач 15.05.1942 – 20.02.1943 Брянск һәм Үзәк фронтларда сугыша. Капитан званиесы алып, 13-нче армия составындагы 280 нче укчы дивизия, 1031 нче укчы полкның 1 нче укчы батальоны командиры булып хезмәт итә. 1943 нче елның февраль уртасында, уңышлы һөҗүм оештырып, Курск өлкәсендәге Черемошное пунктын алган өчен комбат Хафизов беренче хөкүмәт бүләге – **“Кызыл йолдыз”** ордены белән бүләкләнә. Әлеге сугыш барышында Шакир абый икенче тапкыр яралана.

Капитан Хафизов, оста һәм куркусыз командир буларак, аеруча 1943 нче елның җәендә Курск дугасында барган сугышларда танылә. Аның штрафник солдатлардан җыелган батальоны июльнең 5-нән 27-сенә кадәр бертуктаусыз Курск-Орел шоссесының көнчыгыш ягында оборона тота. Курск дугасындагы сугышның беренче көнендә үк немец гаскәрләренең 4 һөҗүмен кире кага. 7-8 нче июль көннәрендә дошман пехотасының танклар белән ясаган 6 атакасын туктата. Бер атна сугышканнан соң Шакир абый батальоныннан 18 солдат кына исән кала. Чиктән тыш кыен шартлар һәм зур югалтуларга карамастан, алар биләгән позицияләреннән чигенмиләр. Курск дугасындагы һәм аннан соңгы сугышлар өчен комбат Хафизов **“Александр Невский”** ордены белән бүләкләнә.

1943 нче елның көзендә иң авыр сугышлар Днепр елгасын кичкәндә була. Сентябрьнең 24 нән 25 нә каршы төнендә көзендә Шакир абый җитәкләгән батальон сугышчылары Чернигов өлкәсе Окунино авылы янында Днепрны беренчеләрдән булып кичеп чыга. Елга аркылы чыкканда алар утырган көймәгә мина төшеп шартлый. Шакир абый ординарецы чәченнән сөйрәп чыкканга гына исән кала. Аргы ярга чыкканнан соң, бер көн эчендә дошманның 14 һөҗүмен кайтарырга туры килә. Шулай итеп, Днепрның уң ярында башка гаскәрләргә кичергә мөмкинлек биргән плацдарм булдырыла. Бу сугышлар өчен комбат Хафизов **“Ленин”** ордены белән бүләкләнә.

1944 нче елның гыйнварында 1 нче Украина фронтының Хәрби Советы капитан Хафизовны **Советлар Союзы Герое** исеменә тәкъдим итә. Шакир абый бу олы бүләккә беренче тапкыр Курск дугасы, икенчесендә – Днепрны кичү сугышлары өчен тәкъдим ителгән була. Ул хезмәт иткән полкның комиссары Г.Н.Фролов әйтүе буенча, Бөек Ватан сугышы дәвамында Шакир абыйга Советлар Союзы Герое исемен бирү мәсьәләсе 9 тапкыр күтәрелә һәм кире кагыла. Авыл картлары сөйләве буенча, моңа югары штабта утыручы бер генералның татарларга карата тискәре мөнәсәбәте сәбәп булган. Шакир абый батальонының штрафной булуы да “файда” итми калмагандыр. Шуңа да карамастан, полк комсоргы Н.Р.Трубаев аның отрядын “иң героик батальон иде” дип бәяли.

1944 нче елның көз-кыш айларында Польшада алып барган сугышлар барышында комбат Хафизовка майор званиесы бирелә. Август башында Развадув дигән шәһәрне алгандагы батырлыгы өчен Шакир абыйга **“Кызыл Байрак”** ордены бирелә. Икенче шундый ук орден белән ул 1945 нче елның гыйнварында дошманның Шидлув шәһәрендәге группировкасын тар-мар иткән өчен бүләкләнә.

Шакир абыйның истәлекләре буенча, бөтен сугыш дәвамында аның өчен иң авыры Одер елгасын кичү була. Аңа һәм сугышчыларына тиз агымлы язгы бозлы суны йөзеп чыгарга туры килә. Ул вакытта батальондагы сугышчыларның яртысы элеккеге моряклар булу нык булыша. Зур югалтулар кичерүгә карамастан, комбат Хафизов солдатлары төп гакәрләр килгәнче ике көн дәвамында тота алганнар.

Комбат Хафизовның соңгы сугышлары 1945 нче елның язында, Берлинны алу операциясе барышында була. Берлиндагы сугышлар өчен Шакир абый тагын бер **“Ленин”** орденына тәкъдим ителә. Бу орден аңа бирелгәнме-юкмы, әлегә ачыклап булмады. Берлин гарнизонының капитуляциясенә бер көн кала, 1 нче май көнне, Шакир абый сугышның соңгы ярасын ала. Сугыш барышында ул барлыгы 4 мәртәбә яралана.

Шакир абый 1946-нчы елда демобилизацияләнә. 1948 нче елда туган авылы Түбән Майнага кайтып төпләнә. 1960 нчы еллар башына чаклы колхоз рәисе булып эшли. Аннан соң, 1970 нче еллар урталарына кадәр авыл советы белән җитәкчелек итә. Аңа кадәр эшләгән җитәкчеләрдән аермалы буларак, халыкка карата йомшак мөнәсәбәте белән аерылып торган. 1982 нче елда Шакир абый балалары янына, Яр Чаллы шәһәренә китеп төпләнә. Шунда 1993 нче елда вафат була. Хәзерге вакытта да авылның өлкән буын вәкилләре Шакир абыйны гел яхшы яктан гына искә алып сөйлиләр.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы***


Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева — Сара Насыйрова
Виктория Нукина — Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина



# Мәктәп хәбәрчесе

**№4** (№24) апрель 2021 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите



Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


## Дәфтәрең ни хәлдә, укучым?!

**/Өлкәннәр киңәше/**



Укучыларның язу дәфтәрләре – аларның йөзе кебек. Дәфтәрдәге язуга, аның торышына, пөхтәлегенә карап, укучының укуга карашы, тырышлыгы, максатка омтылышы турында фикер йөртергә мөмкин.

Кайбер укучыларның дәфтәрләрен кулга алуга – күңел сөенә. Чөнки тышында ук тезелеп киткән матур, тигез хәрефләрдән торган язу. Эчке өлешендә дә, бөтен таләпләр дә үтәлеп, барлык эшләр дә бик пөхтә итеп башкарылган. Ләкин, соңгы елларда, күпчелек укучылар дәфтәрләр торышына тиешле игътибарны биреп бетермиләр шикелле. “Май чүлмәгенең тышыннан билгеле” дигән мәкальдәгечә, аның титул битен алыйк. Кайбер дәфтәрләрнең кемнеке икәнлеген белү өчен, шактый тырышырга кирәк була. Чөнки укучыларның язуы шулкадәр начар, хәрефләрнең элементлары куелып бетмәгәнлектән, хаталы сүзләр килеп чыга. Беренче карашка ук ашыгып, теләмичә генә язылган, дигән фикер туа. Дәфтәрнең эчендә дә буялган, сызылган, өсте-өстенә буяп төзәтелгән урыннар күзгә ташлана. Тигезле-тигезсез почерк, кулдан гына сызылган сызымнар, кыскартып язылган сүзләр – гадәти күренешкә әйләнеп бара. Дәфтәрләрдәге эшләр дә күңел биреп түгел, ә бар булып күренсен өчен генә башкарылган. Менә шушы нәрсәләр нык борчу тудыра да инде.

Үткәргән математика атналыгында да игътибарны дәфтәрләрнең торышына юнәлтергә тырыштым. Эшне җиренә җиткереп башкарырга өйрәнү – алдагы тормыш юлына бер уңайлы шарт кына. Моны мәктәптә эш дәфтәре генә диеп карамасак иде. Үзем укыткан укучылар арасында конкурс та оештырдым. Дәфтәрләре тәртиптә булган укучылар саны аз, билгеле. Алар – 7 нче сыйныфтан Нурматова Зәйнәп белән Минакова Әдилә һәм 5 нче сыйныфтан Йосыпов Рәсим.

Мин ихластан, барлык укучыларның да тырышлык белән, хатасыз, матур, пөхтә язуларын телим. Ризаэддин Фәхреддин дә бит “Тәрбияле бала” әсәрендә шушыларны укучыларга таләп итеп куя. Әгәр алар дәфтәрләрендә эшләрен шушы таләпләрне үтәп башкаралар икән, димәк, укучы балалар башка эшләрне дә шулай, җиренә җиткереп башкарырга кирәклеген аңлыйлар булып чыга. Ә матурлыкны тудыра белгән кеше беркайчан да начар эш-гамәлләр кылмый, кеше хезмәтен бәяли һәм хөрмәт итә белә ул. Барлык укучылар да шуңа омтылсын иде дигән теләктә калам.

***Фәнил Зарипов, математика укытучысы***

## ЮИД командасының чираттагы уңышы

**/Безнең уңышлар/**

28-нче апрель көнне Аксубай районының “Юность” спорт комплексында ЮИД хәрәкәте укучылары арасында “Куркынычсыз тәгәрмәч - 2021” (“Безопасное колесо - 2021”) исемендәге республика конкурсының район этабы үтте. Ул ГАИ хезмәте формалашуына 85 ел тулуга багышланды. Ярыш, көн салкын булуга карамастан, бик кызу үтте. Барлыгы 14 команда катнашты. ЮИДчылар юл йөрү кагыйдәләрен белү, беренче медицина хезмәтен күрсәтү, велосипед төзелеше, иҗади чыгыш, велосипедта фигуралы йөрү этапларында көч сынаштылар. Нәтиҗәдә, безнең мәктәп укучылары “Велосипедта фигуралы йөрү” номинациясендә – 2 нче урын, “2020 - 2021 уку елы нәтиҗәләре буенча иң яхшы ЮИД отряды” номинациясендә 3 нче урынга лаек булдылар. Укучылар грамоталар һәм бүләкләр белән кайттылар. Яшь инспекторларыбызны чираттагы җиңүләре белән котлыйбыз. Киләчәктә аларга тагы да зуррак уңышлар телән калабыз.



**/Укучылар иҗаты/**

### Яз яме

Кояш нурын сибә генә
Һич кызганмый менә.
Шул җылыга кызыгып
Яшел үлән борын төртә.

Кай арада каен кызы
Яшел элгән чугына.
Тузганаклар узышып
Шул кояшта кызына.

Бөтен тирәм берьюлы
Яшеллеккә күмелә.
Ничек болай була ул,
Я, әйтегез, кем белә?

Сыерчыклар оя сайлый
Сандугач өзелеп сайрый.
Игенченең хезмәтенә
Тургай күктә дан җырлый.

Балаларның шат авазы
Урамнарга тарала.
Мондый гүзәл күренеш
Тик авылларда була!

*Самат Гафиятуллин,*
*7 нче сыйныф укучысы.*

**/Күңелле тәнәфес/**

### Тизәйткечләр

Абагага бага-бага,
башым бәрдем баганага.

Җидегәндә җиде кыз,
Җиргә якын ул йолдыз.
Җиргә якын җидегәндә
Җиде йолдыз,җиде кыз.

Кулда тукмак,
Алыйк әле тукмап:
Тукта, тукта, тукмама,
Тукма, тукма, туктама!
Туктап тукмап булмый ул,
Тукмап тукмак тынмый ул.

Торма тора тырмада,
Торна төште тырмага.
Торма, торна, тырмада.
Торна, торма тырнама.

Тукта, тотыйм тырманы,
Торна туктап тормады.
Тотып торам тырманы,
Торна тишкән торманы.

**/Безнең очрашулар/**

## Язучы авылдашыбыз белән очрашу



Безнең мәктәптә һәр ел саен диярлек ниндидер бай эчтәлекле чаралар, укытучылар һәм укучылар өчен җылы очрашулар даими булып тора. Узган айда үзебезнең авылдаш, мәктәбебезнең 1988 нче елгы чыгарылыш укучысы, бүгенге көндә язучы, җәмәгать эшлеклесе, шул ук вакытта татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Алсу апа Нәҗми** (Алсу Мидхәт кызы Нәҗметдинова) белән очрашу бик үзенчәлекле булды. Беренчедән, бу чара туган телләр елын исәпкә алып оештырылса, икенчедән, авылдашыбыз өчен горурлану да иде.

Бу күңелле вакыйганы без каникулдан килүгә үк, 3 нче апрель көнне, Алсу апаның үзе белән киңәшеп билгеләдек. Ул килгәнчегә кадәр укытучылар аның иҗаты белән күпмедер таныштырган булсалар да, әдибәнең үз авызыннан ишетү – күпкә тәэсирлерәк булды. Алсу апа безгә бала чагы, авылда белем алуы турында сөйләде. Укытучыларына мөнәсәбәте бүген дә җылы һәм рәхмәтле икәнлеген киләчәк тормышына юнәлеш биргән беренче укытучысы Морадимова Ильһамия апага багышлаган шигыре аша тойдык. Туган теленә мәхәббәт тәрбияләгән укытучысы Сәкинә апага да олы рәхмәтләрен җиткерде.

Алсу апа үзенең чыгышында бүгенге укучыларга да туган телнең кадере, туган җирнең газизлеген аңлатты. Иҗатында шул темаларны чагылдыруын, туган ягына мәдхия җырлавын шунда тоемладык. Язучы өчен туган җирнең һәр почмагы, анда узган гомернең һәр минуты кадерле икәнлеген белдек.

Очрашуга ямь өстәгән икенче кунагыбыз, мәктәбебезнең 1996 нчы елгы чыгарылыш укучысы, хәзерге вакытта “Шәһри Казан” гәзитенең баш мөхәррире булып эшләүче **Радик абый Сабиров** та килгән иде. Ул чыгышында татар теленең мөһимлеген, туган телнең кыйммәтен укучыларга җиткерергә тырышты. Шулай ук Радик абый да үзен укыткан укытучыларга рәхмәтләрен җиткерде.

Без дә үз чиратыбызда кунакларны буш кул белән каршы алмадык. Башлангыч сыйныф укучылары “Аулак өй” күренешен куйдылар. Югары сыйныфлар Алсу апаның иҗат үрнәкләреннән өзекләр сөйләде. Очрашуның калган өлеш сорау-җавап һәм әңгәмә рәвешендә барды. Ахырдан Иске Татар Әдәмсуы һәм Түбән Майна авыллары китапханәчеләре Равия апа белән Рузилә апалар бик эчтәлеле чыгышлар ясадылар.

Очрашудан без дә, килгән авылдашлар да рухи азык туплап кайттык. Мондый җылы очрашулар һәркем өчен күңел күтәренкелеге өстидер дип уйлыйм. Кунакларга киләчәк тормышларында милли әдәбиятыбызны баетырлык ихтыяр көче, рухи байлык, иҗат чишмәләренең бай булуын теләп калдык.

*Виктория Нукина, IX сыйныф укучысы*

**/Татарстанда туган телләр елы/**

## Бөтенроссия бәйгесендә катнаштым

“Ильһам” – Бөтенроссия күләмендә уздырыла торган иҗат конкурсы. Бу бәйгедә Россиянең төрле төбәкләреннән бик күп кеше катнаша. Конкурста катнашучылар башта зона этабында җиңү яуларга тиешләр. Безнең зона туры Чистай шәһәрендә узган иде. Анда булганда үзем кебек катнашучылар белән очраштым. Чистай турыннан соң мин Казан шәһәренә чакыру алдым. Ничек сөенгәннәремне үзем генә беләм! Чөнки Аксубай районыннан үзем генә Казанга чыктым! Конкурска килүчеләр “Яшь драматург”, “Яшь журналист” һәм “Яшь шагыйрь” номинацияләре буенча көч сынаштылар. Катнашучылар үзләренең бөтен сәләтләрен күрсәттеләр. Аларның кайбер әсәрләре тәҗрибәле һәм атаклы язучыларныкы кебек. Җиңүче үк була алмасам да, лауреат исеменә ирешә алдым.



“Ильһам” конкурсының нәтиҗәләре 23 нче апрельдә Казан физик культура, спорт һәм туризм академиясендә уздырылган зур сәнгать чарасы барышында чыгарылды. Концерт номерларын Татарстанның атказанган җырчылары башкарды. Шул ук көнне, “Ильһам” конкурсында катнашучылар белән бергә, татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадада җиңгән һәм призерлыкка чыккан укучыларны да бүләкләделәр. Бу бәйге бөтендөнья дәрәҗәсендә үткәрелгәнлектән, олимпиадада җиңүчеләр арасында Үзбәкстан, Америка Кушма Штатлары һәм Франция яшьләре дә бар иде. Олимпиада җиңүчеләрен котларга Татарстанның мәгариф министры Илсур Һадиуллин һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов килделәр.

Мин “Ильһам” конкурсында катнашканыма бик шат булдым. Шундый матур һәм дәрәҗәле чарада әле булганым юк иде. Казаннан киләчәктәге иҗат бәйгеләрендә тагы да катнашу нияте белән кайттым.

*Әминә Туктамышева, IX сыйныф укучысы*

## Сөй гомерне, сөй халыкны...



Белгәнебезчә, быелның апрель аенда бөек шагыйрь Габдулла Тукайның 135 яшь тулганын билгеләп үтелде. Әлеге юбилей датасының туган телләр һәм халыкара бердәмлек елы белән туры килүе мәдәни тормышыбызны вакыйгаларга тагын да баетты. Безнең районда да Тукайны искә алып бик күп чаралар һәм конкурслар уздырылды. Мин дә март аенда Габдулла Тукай исемендәге "Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халкыңның дөньясын!" дигән конкурсның муниципаль этабында катнашкан идем. Анда Марсель Галиевның "Туган тел сихәте" әсәреннән өзек сөйләп, өлкән сыйныфлар арасыннан беренче урынны алдым. Шуннан соң 13 нче апрельдә Казанга конкурсның региональ этабына чакырылдым.

Республика дәрәҗәсендәге бәйгеләрдә элек тә катнашканым бар иде. Андый җиргә килеп төшкәч, талантлы яшьтәшләреңнең күплегенә ышанасың. Бу юлы да, беръяктан әдәбиятны үз итүчеләрнең күплеге куандырса, икенче яктан бәйге алдыннан дулкынлану хисен дә арттырды. Чөнки минем яшь төркеменә караган көндәшләр генә дә 45 ләп җыелган иде. Шунлыктан конкурс озакка сузылды, һәм үземнең чират җиткәнне шактый көтәргә туры килде. Шул ук вакытта алданрак ясалган чыгышларны күзәтеп, жюри әгъзаларының аларны ничек бәяләүләрен тыңлап утыруның файдасы зур булды. Чыгышымны башкарганнан соң, сайланып алынган укучылар белән минем дә икенче турга үтүем игълан ителде. Казанның сәнгатьле сөйләү осталары белән ярышуга чакырылуым үзе үк минем өчен зур җиңү булды. Ахыргы турда Гала-концертта чыгыш ясарга әләгә алмавым минем бер дә күңелемне төшермәде. Бу конкурс минем өчен бер дәрес кебек булып, киләчәктә алдынгы урыннар алуга юллар ачты.

*Сара Насыйрова, X сыйныф укучысы*

**/Котлыйбыз!/**




Апрель аенда мәктәбебезнең хөрмәтле укытучылары **Рифкать абый Туктамышев, Илдар абый Сафиуллин, Олеся апа Иванова** гомер бәйрәмнәрен билгеләп узалар. Аларга корычтай нык сәламәтлек, гаилә иминлеге, эшләрендә уңышлар телибез.

I сыйныф укучысы **Хафизов Иректе**, XI сыйныф егетләре **Шәрифуллин Илсаф** белән **Морадимов Илназны** туган көннәре белән котлыйбыз. Аларга укуларында уңышлар, сәламәтлек телибез.